КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 7 август

г.Казань

№ 948

«Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтләрен күрсәтүне финанслауның җан башына нормативларын исәпләү тәртибен һәм 2023 елга «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтләрен күрсәтүне финанслауның җан башына нормативларын раслау турында

2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасында аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган кешеләргә комплекслы булышлык күрсәтеп тору концепциясен тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

«Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтләрен күрсәтүне финанслауның җан башына нормативларын исәпләү тәртибе;

2023 елга «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар һәм «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтләрен күрсәтүне финанслауның җан башына нормативлары

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 7 август, 948 нче
карары белән расланды

## «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтләрен күрсәтүне финанслауның җан башына нормативларын исәпләү тәртибе

### I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 – 2026 елларда «Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүне һәм эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуны оештыру» пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2023 ел, 16 июнь, 727 нче карары белән (алга таба - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 16 июнь, 727 нче карары) расланган 2023 – 2026 елларда «Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүне һәм эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуны оештыру» пилот проектын гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары нигезендә «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә чыгымнарны формалаштыру механизмын билгели.

1.2. «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүгә норматив чыгымнар законнарда билгеләнгән таләпләр нигезендә «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле финанс чаралары күләме булып тора.

1.3. «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүгә финанслауның җан башына нормативы законнарда билгеләнгән таләпләр нигезендә «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүгә норматив чыгымнар нигезендә исәпләнгән финанс чаралары күләме булып тора.

1.4. «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүне финанслауның җан башына нормативларын исәпләү «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүгә тарифны раслау өчен елга бер мәртәбә гамәлгә ашырыла. «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтенә тариф Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 16 июнь, 727 нче карары белән расланган 2023 – 2026 елларда «Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүне һәм эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуны оештыру» пилот проектын гамәлгә ашыру тәртибен һәм шартларын гамәлгә ашыру кысаларында социаль хезмәтләр күрсәтүчене финанслау өчен кулланыла.

1.5. Әлеге Тәртип социаль-хезмәт күрсәтүләр кысаларында «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм «Эшкә

урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтләрен күрсәтүгә финанслауның җан башына нормативларын исәпләү тәртибен билгели.

1.6. «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнар һәм «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтләрен күрсәтүгә финанслауның җан башына нормативлары бер хезмәт күрсәтү өчен билгеләнә.

## II. »Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләү тәртибе

2.1. «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүгә норматив чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:($NFZ_{opt}$)

$$NFZ_{opt} = \frac{(R_{FOT_{str}} + R_{mto} + R_{tr})}{(D_g \times N_{opt})} \times D_{gopt},$$

монда:

$R_{FOT_{str}}$ - социаль хезмәт күрсәтү кысаларында «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүче персонал хезмәтләренең стандарт (база) бәясе;

$R_{mto}$ - «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен матди-техник тәэмин итүгә чыгымнар;

$R_{tr}$ – расходы на транспортные услуги;

$D_g$ - оешманың 244 кә тигез кабул ителә торган елыга эш көннәре саны;

$N_{opt}$ - «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүче персонал берәмлегенә карата «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен алучыларның бишкә тигез кабул ителә торган норматив саны;

$D_{gopt}$ - 81 тигез кабул ителә торган «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтү көннәре саны.

2.2. Социаль хезмәт күрсәтү кысаларында «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүче персонал хезмәтләренең стандарт (база) бәясен исәпләү түбәндәге формула буенча билгеләнә:$R_{FOT_{str}}$)

$$R_{FOT_{str}} = \sum N_{popt} \times O_{str} \times 12 + e,$$

монда:

$N_{popt}$ - бергә тигез кабул итә торган «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүче төп персоналның штат саны нормативы;

$O_{str}$ - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмалары һәм социаль яклау дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карары нигезендә исәпләнә торган социаль хезмәт күрсәтү кысаларында «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүче төп персоналның хезмәте өчен түләү чыгымнары;

12 - елга айлар саны;

e - хезмәт өчен түләү буенча түләүләрне исәпләү чыгымнары.

2.3. «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен матди-техник тәэмин итүгә чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:$R_{mto}$)

$$R_{mto} = R_{tov} + R_{pr},$$

монда:

$R_{tov}$ - элемтә хезмәтләрен, канцелярия товарларын тәэмин итүгә чыгымнар;

$R_{pr}$ - агымдагы башка чыгымнар.

2.4. Элемтә хезмәтләрен, канцелярия товарларын тәэмин итүгә чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:$R_{tov}$)

$$R_{tov} = \left(\sum_{i_1=1}^{n_1} N_{sv} \times C_{sv} + \sum_{i_2=1}^{n_2} N_{kt} \times C_{kt}\right) \times N_{popt},$$

монда:

$N_{sv}$, $N_{kt}$ – әлеге Тәртипнең 1 нче, 2 нче таблицалары нигезендә кабул ителә торган «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүче бер хезмәткәрне элемтә хезмәтләре, канцелярия товарлары белән тәэмин итү нормалары;

$C_{sv}$, $C_{kt}$ – чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда кулланыла торган индекслар-дефляторларны исәпкә алып, план елына кадәрге елның 1 сентябре хәленә карата азык-төлек булмаган товарларның уртача базар кыйммәте нигезендә кабул ителә торган элемтә хезмәтләре, канцелярия товарлары белән тәэмин итү нормалары исемлегендә товар бәясе;

$n_1$, $n_2$ – әлеге Тәртипнең 1 нче, 2 нче таблицалары нигезендә кабул ителә торган «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүче хезмәткәрне элемтә хезмәтләре, канцелярия товарлары белән тәэмин итү өчен товарлар һәм хезмәтләр саны;

$i_1$, $i_2$ – әлеге Тәртипнең 1 нче, 2 нче таблицалары нигезендә кабул ителә торган «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүче бер хезмәткәрне элемтә хезмәтләре, канцелярия товарлары белән тәэмин итү өчен товарлар һәм хезмәтләр саны;

$N_{popt}$ - бергә тигез кабул итә торган «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүче төп персоналның штат саны нормативы.

1 нче таблица

Элемтә хезмәтләре белән тәэмин ителеш нормалары

| Т/с | Хезмәтнең төре | Үлчәү берәмлеге | Тәэмин ителеш нормасы |
|---|---|---|---|
| 1. | Автоматлаштырылган шәһәрара телефон элемтәсе | елга бер хезмәткәргә минут | 45 |
| 2. | Телефон | бер хезмәткәргә номерлар саны | 0,1 |
| 3. | Интернет | елга түләүләр саны | 12 |

2 нчы таблица

Канцелярия товарлары белән тәэмин ителеш нормалары (елына бер хезмәткәргә)

| Т/с | Товар атамасы | Үлчәү берәмлеге | Тәэмин ителеш нормасы |
|---|---|---|---|
| 1. | Тизтеркәгеч | данә | 4 |
| 2. | Кәгазьләр өчен папка | данә | 4 |
| 3. | Маркер | төргәк | 0,5 |
| 4. | Принтер өчен кәгазь | кап | 0,2 |
| 5. | Карандаш | данә | 4 |
| 6. | Карандаш өчен грифель | данә | 4 |
| 7. | Каләм | данә | 4 |
| 8. | Стержень | данә | 4 |
| 9. | Бозгыч | данә | 1 |
| 10. | Җилем | данә | 0,5 |
| 11. | Линейка | данә | 1 |
| 12. | Штрих | данә | 1 |
| 13. | Кыстыргыч | тартма | 1 |
| 14. | Ябыштыру тасмасы | данә | 1 |
| 15. | Кайчы | данә | 0,5 |
| 16. | Блокнот | данә | 2 |
| 17. | Көндәлек | данә | 1 |
| 18. | Факс өчен кәгазь | кап | 0,1 |

2.5 Башка агымдагы чыгымнар ($R_{pr}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$R_{pr} = (R_{FOT_{str}} + R_{tov}) \times K_{pr},$$

монда:

$R_{FOT_{str}}$ - социаль хезмәт күрсәтү кысаларында «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүче персонал хезмәтләренең стандарт (база) бәясе;

$R_{tov}$ - элемтә хезмәтләрен, канцелярия товарларын тәэмин итүгә чыгымнар;

$K_{pr}$ - 0,04 тигез кабул ителә торган башка агымдагы чыгымнарга түләүләр коэффициенты.

2.6. Транспорт хезмәтләренә чыгымнар $R_{tr}$) (түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$R_{tr} = (R_{gsm} + R_{prt}) \times N_{prb} \times D_g,$$

монда:

$R_{gsm}$ - ягулык-майлау материалларына чыгымнар;

$R_{prt}$ - транспорт чарасына башка чыгымнар;

$N_{prb}$ - 30 км га тигез булган көненә йөреш нормасы;

$D_g$ - оешманың 244 кә тигез кабул ителә торган елыга эш көннәре саны.

2.7. 1 км йөрешкә ягулык-майлау материалларына чыгымнар (Rgsm) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$R_{gsm} = \frac{Q_{norm}}{100} \times C_{top} \times K_{masl},$$

монда:

$Q_{norm}$ - ягулыкның түбәндәге формула буенча билгеләнә торган транспорт чарасы белән норматив чыгымы:

$$Q_{norm} = Q_{baz} \times (1 + 0{,}01 \times K),$$

монда:

$Q_{baz}$ - ягулы чыгымының база нормасы, 100 км га литр;

K - нормага карата төзәтү коэффициенты (суммар чагыштырма өстәү яисә киметү);

$C_{top}$ - Федераль дәүләт статистика хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы мәгълүматлары нигезендә кабул ителә торган автомобиль ягулыгының алдагы чор ахырына уртача статистик бәясе, сум;

$K_{masl}$ - 1,08 тигез кабул ителә торган автомобиль майларына һәм майлауларга чыгымнар коэффициенты.

Зурлыклар$Q_{baz}$ һәм K Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Автомобиль транспортында ягулык һәм майлау материаллары тоту нормалары» методик тәкъдимнәрен гамәлгә кертү турында» 2008 елның 14 мартындагы АМ-23-рб номерлы боерыгында күрсәтелгән нормалар нигезендә кабул ителә.

2.8. Транспорт чарасының 1 км йөрешенә башка чыгымнар$R_{prt}$) (түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$R_{prt} = R_{gsm} \times K_{prt},$$

монда:

$R_{gsm}$ - ягулык-майлау материалларына 1 км йөрешкә чыгымнар;

$K_{prt}$ - башка чыгымнарның өлешен исәпкә ала торган һәм 0,07 тигез кабул ителә торган коэффициент.

## III. »Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүне финанслауның җан башына нормативларын исәпләү тәртибе

3.1. «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтне финанслауның җан башына норматив бер хезмәт өчен билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча билгеләнә:($PNF_{opt}$)

$$PNF_{opt} = NFZ_{opt},$$

мондаNFZ$_{opt}$ - «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүгә норматив чыгымнар.

## IV. Хезмәт күрсәтүне финанс белән тәэмин итүне исәпләү тәртибе «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү»

4.1. «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүне финанс белән тәэмин итү чыгымнарыFO$_{opt}$) (түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$FO_{opt} = \sum NFZ_{opt} \times N_{fopt},$$

монда:

$NFZ_{opt}$ - «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүгә норматив чыгымнар;

$N_{fopt}$ - «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен алучыларның планлы саны.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 7 август, 948 нче
карары белән расланды

2023 елга «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар һәм «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтләрен күрсәтүне финанслауның җан башына нормативлары

1. 2023 елга «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар бер хезмәт өчен 40 272,64 сум күләмендә билгеләнә.

2. 2023 елга «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүгә финанслауның җан башына нормативы бер хезмәт өчен 40 272,64 сумга тигез итеп кабул ителә.

3. 2023 елга «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен алучыларның планлы саны 60 берәмлек күләмендә кабул ителә.

___